ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Әлки муниципаль районы
Иске Камка авыл җирлеге
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет Старокамкинского
сельского поселения
Алькеевского муниципального района

Адресы: 422897, ТР, Әлки районы, Иске Камка авылы, Түбән урамы,1 йорт
тел./факс 8(84346) 73-524

Адрес: 422897, РТ, Алькеевский район, с. Старое Камкино, ул.Нижняя. д.1
тел./факс 8(84346) 73-524

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Иске Камка авылы **КАРАР**

**2021 елның 13 апреле** **6№**

## Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге территориясендә гражданнарның беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүдә катнашу рәвешләренең якынча исемлеген билгеләү турында

1994 елның 18 ноябрендәге "Янгын куркынычсызлыгы турында" 69-ФЗ номерлы, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "131-ФЗ номерлы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге территориясендә гражданнарның беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүдә катнашуының рәвешләрен билгеләү максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлеге территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүдә гражданнарның катнашу рәвешләре түбәндәгеләр булырга мөмкин:

ирекле янгын сагы эшчәнлегендә катнашу;

янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә социаль әһәмиятле эшләр башкару;

эштә һәм көнкүрештә янгынга каршы режим кагыйдәләрен үтәү;

алар милкендә булган биналарда һәм корылмаларда беренчел янгын сүндерү чаралары булу;

янгын чыккан очракта кичекмәстән алар турында Дәүләт янгынга каршы хезмәтенә хәбәр итү;

Дәүләт янгынга каршы хезмәте килгәнче кешеләрне, мөлкәтне коткару һәм янгын сүндерү буенча көченнән килгәнчә чаралар күрү;

янгын сүндергәндә Дәүләт янгынга каршы хезмәтенә ярдәм күрсәтү;

Дәүләт янгын күзәтчелеге вазыйфаи затларының күрсәтмәләрен һәм башка законлы таләпләрен үтәү;

законнар белән билгеләнгән тәртиптә Дәүләт янгын күзәтчелеге вазыйфаи затларына янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлешен тикшереп тору һәм аларны бозуларны булдырмау максатларында аларга караган җитештерү, хуҗалык, торак һәм башка биналарны һәм корылмаларны карау һәм тикшерү уздыру мөмкинлеге бирү.

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми //htth:pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлки муниципаль районы
Иске Камка авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: Ф.А.Акберов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОКАМКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ОГРН 1061665001804 ИНН 1605004301